ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.12.2020 ел Баулы шәһәре №232

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «2020-2021 уку елында Баулы муниципаль районы мәгариф учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итү турында»гы 2020 елның 1 сентябрендәге 176 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Айлык акчалата һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 2019 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карары, «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар аш белән тәэмин итү турында» 2020 елның 6 октябрендәге 908 номерлы карары нигезендә билгеләнгән башка төр түләүләрне индексацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «2020-2021 уку елында Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре укучыларын кайнар аш белән тәэмин итү турында»гы 2020 елның 1 сентябрендәге 176 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2нче пунктта:

өченче абзацта «51 сум 85 тиен» саннарын һәм сүзләрен «53 сум 41 тиен» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «7 сум 70 тиен» саннарын һәм сүзләрен «8 сум 00 тиен» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «35» санын «43» санына, «25» санын «33» санына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә: “-1-4 сыйныф укучылары өчен шәһәрдә иртәнге аш - 15 сум, озайтылган көн төркемендә туклану - 20 сум; авылда иртәнге аш - 15 сум.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинга йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров